**Күңелле сюрпризлар көне.**

Бәзәкә мәдәният йорты 2.07.2019ел.

Икенче июль – сюрпризлар көнен без дә балалар белән билгеләп утәргә уйладык. Балалар алдан ук бер – берсенә сюрприз әзерләргә булдылар. Менә шунда сорау туды? Нәрсә соң ул сюрприз? Балаларның күбесе сюрприз ул - бүләк дип җавап бирде, әзерләгән бүләкләре белән алыштылар. Азалия Мөхетдинова сюрприз ул бүләк кенә түгел, ә якын кешеңне ниндидер гамәл белән сөендерү диде.Энеләре Алмаз һәм Артур белән бик матур плакат әзерләп, велопрогулка оештыручыларга рәхмәтләрен җиткерделәр. Райнур Исмәгыйлевның да җавабы кызыклы иде: кешеләргә көтмәгәндә яхшылык эшләп, аларга елмаю бүләк итсәң-менә дигән сюрприз була диде.Без озак уйлап тормыйча шулай эшләдек тэ. Йорәк формасындагы шарларны урамда очраган авылдашларга бүләк итәргә уйладык. Сюрприз чыннан да бик матур килеп чыкты. Абыйлар, апалар, эбиләр, балалар бик сөенделәр: “Узебезнең якыннарыбызга да берәр сюрприз эзерлибез болай булгач,”-диделәр...

Әйдәгел киләчәктә дә якыннарыбызга, күршеләребезгә, авылдашларыбызга яхшы гамәлләребез белән елмаю бүләк итеп яшик!

(Г.Гумерова)




«Бизякинский
дом
культуры»







ВЕЛОПРОГУЛКА
УРА!
ТАК ДЕРЖАТЬ
БИЗЯКИ


SUNSHINE











https://www.youtube.com/watch?v=kVKHATfHQRY&feature=youtu.be